# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге составына керүче Түбән Бикмәт торак пунктында 2021 елда үзара салым кертү турында

**2020 елның 14 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Түбән Бикмәт авылында гражданнар җыены

## КАРАР БИРДЕ:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге территориясендә Түбән Бикмәт торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, I төркем инвалидлардан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым кертү.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- Түбән Бикмәт т. п. урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу);
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Түбән Бикмәт авылында каты көнкүреш калдыкларын чистарту буенча (килешү буенча эш өчен түләү) хезмәт күрсәтү;
- район газетасы «Сарман»да некрологларны бастырып чыгару.

3. Әлеге карарны Кәүҗияк авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы Ф. Ә. Хөснетдинов